Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

«22» ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 22 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бикүле авылы чикләрендә Зеленая урамында юлны ремонтлау (грунт-вак таш түшәү, вак таш салу)

- Күперне төзекләндерү;

- Бикүле авылы су башнясына диспетчерлык пункты алып урнаштыру мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 400 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 224 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 216 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 8 катнашучысы тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлегенең Бикүле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2022 елда 1500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бикүле авылы чикләрендә Зеленая урамында юлны ремонтлау (грунт-вак таш түшәү, вак таш салу)

- Күперне төзекләндерү;

- Бикүле авылы су башнясына диспетчерлык пункты алып урнаштыру мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль

районының Бикүле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Бикүле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова